# Салимуллина Фатима Хөббихуҗа кызы

Әнием Салимуллина (Шафигуллина) Фатима 1926 елның 3 декабрендә Маһирә әби белән Хөббихуҗа бабайның гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. 8 яше тулгач мәктәпкә укырга керә, ләкин 7 нче классны тәмамларга насыйп булмый аңа.

Илдә зур кайгы - сугыш башлана. Бабайны 1941 елның июлендә сугышка алалар, әби дүрт бала белән ялгыз кала. Озак та үтми әнине дә урман кисәргә җибәрәләр, өс-баш начар, чабаталары җиргә бозланып ката, ә шулай да 15 яшьлек кыз урман кисә. 16 яшь тулуга әнине сугышка киткән ирләрне алыштыру өчен **Бондюг МТС да тракторга утырталар**. Өч яшь кыз **Шафигуллина Фатима** (әни), **Зиннатуллина Мөгәлимә**, **Ганиева Мәүгидә** апалар көн-төн колхоз басу кырларын сөрә, чәчә.

Сугыш бетеп, тормышлары яхшыруга өмет итеп бушка эшли алар. 1947 елда әнием этием Салимуллин Миннәхмәт белән тормыш кора. Кияүгә чыккач кына тамагым ипигә, өстем алмаш киемгә туйды, дип искә ала иде әни. Озак еллар бер йортта килендәше Салимуллина Миниямал белән яшәргә насыйп була әнигә. Бик кешелекле, игелекле була әнигә карата дәү әни “яшерә-яшерә ашата иде мине” -дип сөйли иде әниебез.

Бер-бер артлы балалар туа, гаилә ишәя, әбиебез Сабехиямал каты авырудан интегеп 2 елда 6 ай урын өстендә ятып эти белән әни тәрбиясендә 1959 елның июлендә бакыйлыкка күчә. Әни ул вакытта күберәк төзелеш эшендә йөри, ферма, клуб, мәктәп салуда эшли. 1964 елдан “Кама” колхозы складында мөдир вазифасын башкара. Көндезләрен трактор, машина, комбайннарны төзәтергә запчасть бирсә, кичләрен отчет-чутлау эше белән утыра. 1971 елда колхозда трактористлар курсы ачылу белән беренчеләрдән булып укырга керә. 1972 елның апрелендә алты кыю хатын кыз “тимер ат” руле артына утыра. “Беренче карлыгачлар” бригадасы даны еракларга тарала. Татарстанда алар турында горурланып телевидение, радиодан сөйләделәр, рәсемнәре, исемнәре газета-журнал битләрендә урын алып торды. Үз алларына куелган план-йөкләмәне алар арттырып үтәделәр. Хөкүмәтебез тракторист хатын-кызларның хезмәтен уңай бәяли, күп санлы бүләк, мактау кәгазьләренә, медальләргә лаек була алар.

Коммунист Салимуллина Фатима 1973 елда “ За трудовые отличия” медале белән бүләкләнә, 1974 елда Краснодар шәһәрендә узган Бөтенсоюз механизатор хатын-кызлар слетында катнаша.

1974 елның 8 мартында Казан телевидениесендә чыгыш ясый. 1975 елда Мәскәү ВДНХ слетында катнаша һәм 1976 елда әниебезнең фотосы Алабуга район почет тактасында Ленин мәйданында урын ала.

1977 елда “Хезмәт ветераны” медаленә лаек була. Шулай ук күп балалы гаиләләр өчен бирелә торган медальләр әниебезнең күкрәген бизи: “Медаль

материнства II степени” (23.11.1958), “Медаль материнства I степени” (21.03.1961) , “Материнская слава III степени” (19.09.1963).

1976 елда әниебез пенсияга чыга, ләкин колхоз җитәкчеләребез үтенече буенча ашлык амбарларында мөдир вазифасын башкара.

Орлык сайлау, саклау, киптерү, маллар өчен фураж әзерләүдә көчен кызганмыйча эшли ул.

Иң мөһиме, әниебез 1985 елда Хөббихуҗа бабабыз сугышкан һәм

һәлак булган Калуга өлкәсе Спас-Доминский районы туганнар каберлегендә җирләнгән әтисенең каберен күрү бәхетенә ирешә, чәчәк бәйләме, авылыбызның туфрагын сала. Бабабызның исеме язылган Мәңгелек ут янында догалар кыла.

1992 ел 15 июнь көнне әниебезне мәңгегә югалттык, аның якты, матур истәлекләре күңел түребездә саклана. Авылдашларыбыз, күршеләребез әле хәзер дә әнине яхшы яклап кына искә алалар.

Урыннарыгыз җәннәт түрләрендә булып, укыган догаларыбыз барып ирешсә иде сезгә, вафат булган тракторчы кыю йөрәкле хатын-кызларыбыз.

Исән булган апаларыбызга саулык, гаилә бәхете насыйп булсын иде дигән теләк белән ***Зөһрә Миннәхмәт кызы Салимулина. 2022 ел, март.***

Салимуллина Фатима



Бөтенсоюз механизатор хатын-кызлар слеты Краснодар шәһәрендә



1974 ел 8 март Казан телевидениесендә



1972 ел апрель “Беренче карлыгачлар” бригадасы



# Тракторда—хатын-кызлар

**РЕПОРТАЖ**

...колхоз меха- таналы булды. Иртән ир-
...тракторчылар маши-
...лылар,

1975 ел.



Коммунист Салимуллина Фатима 1973 елда “ За трудовые отличия” медале белән бүләкләнә



1975 г.



Гаилә 1987 ел




Ветеран труда



За трудовое отличие




Орден Материнской славы



Медаль материнства 1 степени



Медаль материнства 2 степени



От имени Президиума Верховного Совета СССР Указом Президиума Верховного Совета

Татарской АССР от 30/VII 1958 г.

награждена медалью

„Медаль материнства"

II степени

Секретарь Президиума Верховного Совета

М. П.

23 октября 1958 года

Г № 748266

ПОЛОЖЕНИЕ

о медали „Медаль материнства"

(Утверждено Указом Президиума Верховного Совета СССР от 18 августа 1944 г.).

1. Медалью **„Медаль материнства"** награждаются матери, родившие и воспитавшие пять и шесть детей.

2. Награждение медалью **„Медаль материнства"** производится от имени Президиума Верховного Совета СССР Указами Президиумов Верховных Советов союзных и автономных республик.

3. Медаль **„Медаль материнства"** состоит из двух степеней:

**„Медаль материнства"** I степени;

**„Медаль материнства"** II степени.

Высшей степенью медали является I степень.

4. Медалью **„Медаль материнства"** награждаются:

матери, родившие и воспитавшие пять детей,— медалью II степени;

матери, родившие и воспитавшие шесть детей,— медалью I степени.

5. Награждение медалью **„Медаль материнства"** соответствующей степени произво-

5







